**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 14 июнь № 386

г. Казань

2017 – 2020 елларга Татарстан Республикасында кадетлар белеме бирүне үстерү концепциясе турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 ел, 29 декабрь, ФЗ-273 нче Федераль законны үтәү йөзеннән һәм кадетлар белеме бирү нәтиҗәлелеген арттыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2017 – 2020 елларга Татарстан Республикасында кадетлар белеме бирүне үстерү концепциясен (карарга теркәлә) расларга.
2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына ике атна эчендә 2017 – 2020 елларга Татарстан Республикасында кадетлар белеме бирүне үстерү концепциясен гамәлгә ашыру буенча чаралар планын расларга.
3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\386.doc

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2017 ел, 14 июнь, 386 нчы
карары белән расланды

**2017 – 2020 елларга Татарстан Республикасында кадетлар белеме бирүне үстерү концепциясе**

2017 – 2020 елларга Татарстан Республикасында кадетлар белеме бирүне үстерү концепциясе (алга таба – Концепция) – төбәк дәүләт мәгариф сәясәте өлкәсендәге стратегик документ. Ул 2017 – 2020 елларга укыту, тәрбия бирү, үстерү буенча зур потенциалга ия әһәмиятле социаль-педагогик, социомәдәни күренеш буларак республикада кадетлар белеме бирүне үстерүнең гомуми векторын һәм өстенлекле юнәлешләрен билгели.

Концепция илебезнең гомуми белем бирү системасында хәзерге заман шартларында өстенлекле юнәлешләрнең берсе булырга мөмкин һәм тиешле кадетлар белеме бирүне камилләштерүгә һәм аның нәтиҗәлелеген арттыруга юнәлдерелгән. Ул Россия Федерациясендә һәм Татарстан Республикасында кадетлар белеме бирүнең торышын һәм тенденцияләрен анализлау нигезендә эшләнде.

Концепциядә түбәндәгеләр ачыла:

Татарстан Республикасында кадетлар белеме бирүнең хәзерге көндә торышы;

Татарстан Республикасында кадетлар белеме бирүне үстерүнең төп бурычлары һәм юнәлешләре;

Концепцияне тормышка ашырудан көтелә торган нәтиҗә.

Концепция Татарстан Республикасында кадетлар белеме бирүне үстерү программасын эшләү өчен нигез булып тора.

Концепциядә файдаланыла торган төп төшенчәләр:

кадетлар корпусы — хәрби-патриотик тәрбия бирү, балаларны һәм яшьләрне хәрби хезмәткә һәм граждан хезмәтенә әзерләү максатларында төп гомуми һәм гомуми урта белем бирүнең мәгариф программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган гомуми белем бирү оешмасы;

кадетлар интернат мәктәбе — төп гомуми һәм гомуми урта белем бирүнең мәгариф программалары белән бергә өстәмә гомуми үстерүче программалар буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган, укучылар өчен яшәү шартлары булдырылган гомуми белем бирү оешмасы;

кадетлар мәктәбе — төп гомуми һәм гомуми урта белем бирүнең мәгариф программалары белән бергә өстәмә гомуми үстерүче программалар буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган гомуми белем бирү оешмасы;

кадетлар сыйныфлары — төп гомуми һәм гомуми урта белем бирүнең мәгариф программалары белән бергә өстәмә гомуми үстерүче программаларны гамәлгә ашыра торган гомуми белем бирү оешмаларында булдырылган кадетлар белеме бирү сыйныфлары;

кадет — кадетлар сыйныфында, кадетлар мәктәбендә һәм кадетлар интернат мәктәбендә белем бирү процессында катнашучы, кадет интеллектуаль, мәдәни,

физик һәм рухи үсеше нигезендә гражданнар даирәсендә һәм хәрби даирәдә һөнәри яктан Ватанга хезмәт итәргә әзерләнә.

## I. Татарстан Республикасында кадетлар белеме бирү системасының хәзерге көндә торышы

Төбәктә гомуми белем бирү (шул исәптән дәүләт) оешмалары нигезендә төрле типтагы һәм юнәлештәге кадетлар белеме бирү оешмалары челтәре формалаштырылган:

11 кадетлар интернат мәктәбе,

3 кадетлар мәктәбе,

1 кадетлар корпусы.

Республикада кадетларның гомуми саны 4 мең кешедән артык тәшкил итә. Социаль составы буенча: 36,6 процент — тулы булмаган гаиләләрдән балалар, 3,2 процент — ятим балалар һәм опекада булган балалар, 17,8 процент — күп балалы гаиләләрдән балалар, 1,9 процент — имин булмаган гаиләләрдән балалар, 1,7 процент — хәрби хезмәткәрләр балалары.

Татарстан Республикасының 12 муниципаль гомуми белем бирү оешмасында кадетлар сыйныфлары эшләп килә, аларга җәлеп ителгәннәрнең гомуми саны 2 000 укучыдан артык, шул исәптән Казан (4), Буа (1), Чаллы (1), Әлмәт (2), Алабуга (1) шәһәрләрендә , Алексеевск (1), Лаеш (2) муниципаль районнарында.

Шулай итеп, Татарстан Республикасында кадетлар белеме бирү моделе формалаштырылган, һәм анда белем бирү оешмаларын төп гамәлгә куючылар булып Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы яки Татарстан Республикасының башкарма комитетлары тора. Кадетлар белеме бирү моделе үз эченә түбәндәгеләрне ала:

кадетлар корпусы;

гамәлгә куючы карары нигезендә башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү һәм һөнәри белем алдыннан профильле белем бирү программаларын гамәлгә ашыра торган, 1 (5) сыйныфтан алып 11 сыйныфка кадәр тәрбияләнүчеләрне интернатта карап тоту һәм тулы пансион яки өлешчә пансион (туклану гына) мөмкинлеге булган кадетлар интернат мәктәпләре (кадетлар мәктәпләре);

кадетларга белем бирү түгел, кадетларга тәрбия бирү оешмасы булган, төп һәм өстәмә программаларның тирәнтен спорт һәм хәрби-патриотик юнәлеше белән төп гомуми, урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыра торган, 5 сыйныфтан алып 11 сыйныфка кадәр кадетлар сыйныфлары булган гомуми белем бирү мәктәпләре һәм муниципаль дәрәҗәдәге кадетлар сыйныфлары.

Тулаем алганда, ел саен кадетлар белеме бирү оешмаларын тәмамлаучыларның якынча 25 проценты дәүләт оборонасы һәм иминлеге, законлылыкны һәм хокук тәртибен тәэмин итү йөзеннән кадрлар әзерләүне гамәлгә ашыручы югары белем бирә торган мәгариф оешмаларында укуларын дәвам иттерәләр.

Россия Федерациясе Президентының Идел буе федераль округындагы тулы

вәкаләтле вәкиле аппараты гамәлгә ашыра торган «КаДетство» проекты республикада кадетлар белеме бирүне үстерүдә иң мөһим этәргеч булды, аның кысаларында 2014 елда Түбән Кама шәһәрендә «Советлар Союзы Герое Гани Сафиуллин исемендәге Идел буе федераль округының Татарстан кадетлар корпусы» ачылды. Анда 250 кеше укый, шулардан 72 процент — Татарстан Республикасы муниципаль районнарыннан балалар. Өстәмә белем бирү программалары түбәндәге юнәлешләр буенча гамәлгә ашырыла: хәрби-патриотик, техник, физкультура-спорт, сәнгати-эстетик, лингвистика һәм культурология, табигать-фәнни.

Татарстан Республикасында кадетлар белеме бирүне үстерү концепциясен эшләү стратегик мәгариф проектында китерелә. Аның актуальлеге кадетлар белеме бирү эшчәнлегенең ихтыяҗын, нәтиҗәлелеген һәм шуның белән бергә аны республикада үстерү зарурлыгын билгели торган түбәндәге социаль, мотивацион-кыйммәти факторлар комплексы булуына бәйле:

тагын да нәтиҗәле булырга мөмкин һәм тиешле мөһим социаль-педагогик институт буларак кадетлар белеме бирүгә арта барган таләпләр;

заманның яңа таләпләрен, хәзерге заман социомәдәни үсеше шартларын, тенденцияләрен һәм үзенчәлекләрен адекват рәвештә чагылдыра торган кадетлар белеме бирүнең бербөтен системасын формалаштыруга объектив ихтыяҗ;

республиканың педагогик һәм идарәчелек кадрларының тупланган тәҗрибәсеннән, компетенция дәрәҗәсеннән оптималь файдалану нәтиҗәсендә ачыла торган кадетлар белеме бирү системасы үсешенең яңа мөмкинлекләре, шулай ук кадетлар белеме бирү оешмаларының ресурслар, мәгълүмати, уку-укыту-методик, тәрбияви, үстерү потенциалын көчәйтүнең реаль мөмкинлекләре;

кадетлар белеме бирү, укучы шәхесен үстерү, аның рухи-әхлакый һәм социаль тәҗрибәгә ия булу бурычларын хәл итүдә җәмәгать институтлары, ведомстволар һәм оешмалар катнашуын активлаштыру зарурлыгы.

Үткәрелгән SWOT-анализ Татарстан Республикасында кадетлар белеме бирүне үстерүнең көчле һәм көчсез якларын билгеләде.

**SWOT-анализ**

| | |
|---|---|
| **S**<br>**Татарстан Республикасында кадетлар белеме бирүне үстерүнең көчле яклары**<br>Төрле төрдәге һәм юнәлештәге кадетлар белеме бирү оешмаларының инновацион эшчәнлегенең шактый зур тәҗрибәсе;<br>кадетлар белеме бирү оешмалары белән җәмәгатьчелек, мәгариф мөнәсәбәтләре субъектлары кызыксынуының югары дәрәҗәсе (социологик тикшеренүләр мәгълүматлары);<br>кадетлар белеме бирү һәм аны | **W**<br>**Татарстан Республикасында кадетлар белеме бирүне үстерүнең көчсез яклары**<br><br>Кадетлар белеме бирүне үстерүнең норматив-хокукый тәэмин ителеше җитәрлек дәрәҗәдә эшләнелмәве;<br>кадетлар белеме бирү һәм аны үстерү өлкәсендә комплекслы психологик-педагогик тикшеренүләр булмавы;<br>вариативлыгын һәм «кадет дисциплиналары» үзенчәлекләрен |

| | |
|---|---|
| үстерү белән бәйле мәсьәләләр өлкәсендә дәүләт, бизнес-берләшмәләр, җәмәгатьчелек көчләрен берләштерү;<br>кадетлар белеме бирү оешмаларында укучыларны тәрбияләү һәм аларның социальләшүе системасына юнәлдерелә торган финанс ресурсларының шактый җитәрлек күләме;<br>кадетлар белеме бирүне үстерү өлкәсендә заманча проектлар эшләргә һәм гамәлгә кертергә сәләтле эре мәгариф һәм тикшеренү үзәкләре булуы;<br>укучыларны тәрбияләү һәм аларның социальләшүе федераль һәм төбәк проектлары эшләү тәҗрибәсе;<br>тәрбия бирү системасының үсеш алган төбәк һәм этномәдәни өлешләре | исәпкә алып, белем бирү процессын уку-укыту-методик тәэмин итү дәрәҗәсе җитәрлек булмавы;<br>тәрбия һәм өстәмә белем бирү өлкәсендә кадетлар белеме бирү системасының педагогик һәм җитәкче кадрларының квалификациясен күтәрү һәм аларны яңадан әзерләү буенча нәтиҗәле система булмавы;<br>матди-техник базаны яңарту дәрәҗәсе җитәрлек булмавы;<br>кадетлар белеме бирү сыйфатына һәм укучыларның шәхси нәтиҗәләргә ирешүенә диагностика һәм мониторинг тикшеренүләре системасының җитәрлек дәрәҗәдә эшләнгән булмавы;<br>соңгы нәтиҗәләр буенча тәрбия бирү эшчәнлеген матди стимуллаштыру системасы булмавы;<br>кадетлар белеме бирү оешмаларына укучыларны сайлап алу һәм кабул итүгә бердәм таләпләр булмавы;<br>кадетлар белеме бирү оешмаларында сәләтле балаларны билгеләү һм алар белән эшләү системасының камил булмавы |
| **O**<br>**Татарстан Республикасында кадетлар белеме бирүне үстерүдә мөмкинлекләр**<br>Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең мәгариф системасын, шул исәптән кадетлар белеме бирүне үстерү мәсьәләләренә зур игътибары;<br>кадетлар белеме бирү оешмаларында тәмамлап чыгучыларны әзерләү сыйфатын һәм аларның конкурентлык сәләтен арттырырга мөмкинлек биргән яңа укыту, тәрбияләү һәм үстерү формаларын эчтәлек ягыннан баету һәм куллануны киңәйтү;<br>кадетлар белеме бирүне актив үстерүгә җәмгыятьнең арта барган таләпләре; | **T**<br>**Татарстан Республикасында кадетлар белеме бирүне үстерүдә куркынычлар**<br>Кадетлар белеме бирүне үстерүнең норматив-хокукый тәэмин ителешенең камил булмавы;<br>кадетлар белеме бирү оешмаларын тәмамлап чыгучыларны әзерләү дәрәҗәсенә бердәм таләпләр булмавы;<br>кадетлар белеме бирү системасы белән идарә итүнең бербөтен һәм нәтиҗәле системасы булмавы;<br>матди-техник базаның, спорт һәм медицина ягыннан тәэмин ителешнең җитәрлек дәрәҗәдә булмавы;<br>кадетлар белеме бирү оешмаларында педагогик кадрларны сайлап алу һәм |

| | |
|---|---|
| кадетлар белеме бирү оешмаларының һәм социаль партнерларның, шул исәптән бизнес-берләшмәләрнең үзара хезмәттәшлеге һәм интеграциясенең зур потенциалы;<br>кадетлар белеме бирү сыйфатын тикшерүдә тотуның, кадетлар белеме бирү оешмалары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләүнең яңа формаларын һәм ысулларын гамәлгә кертү;<br>белем бирү процессына актив рәвештә мәгълүмати-коммуникатив технологияләрне кертү;<br>өстәмә һөнәри белем бирү системасының нәтиҗәлелеген арттыру | әзерләүнең сыйфатлы системасы булмавы;<br>кадетлар белеме бирү, аның ресурслар белән тәэмин ителеше торышы һәм проблемалары буенча системалы фәнни тикшеренүләр булмавы |

## II. 2017 – 2020 елларга Татарстан Республикасында кадетлар белеме бирүне үстерүнең төп бурычлары һәм юнәлешләре

Хәзерге көндә кадетлар белеме бирү социаль-педагогик күренеш буларак үз эчендә түбәндәгеләрне берләштерә:

шәхси яктан әһәмиятлелек – үз-үзеңә кыйммәти мөнәсәбәт һәм лидер – булачак командир, җитәкче, оештыручы, дәүләт (хәрби һәм граждан) хезмәткәре сыйфатларын формалаштыру;

иҗтимагый әһәмият – коллективларда, җәмгыятьтә адекват рәвештә җайлашырга мөмкинлек бирә торган иптәшлек, кадетлар тугандашлыгы, җаваплылык формалаштыру;

дәүләт әһәмияте – профессиональлек, карьера үсеше, Ватанга лаеклы хезмәт итү мөмкинлеген формалаштыру һәм аның илкүләм иминлеген тәэмин итү факторы буларак белем бирү.

Республикада кадетлар белеме бирүне үстерү максаты хәрби даирәдә дә, гражданнар даирәсендә дә лаеклы урын табарга сәләтле, югары белемле, рухи-әхлакый шәхесне укыту, тәрбияләү һәм үстерүнең максатчан, нәтиҗәле процессын тәэмин иткән профильле белем бирүнең оптималь системасын төзүдән гыйбарәт.

Кадетлар белеме бирүне үстерүнең бурычлары:

1. Кадетлар белеме бирү төбәк системасының бердәм концептуаль һәм норматив-хокукый киңлеген төзү.

2. Кадетлар белеме бирү белән идарә итү системасын камилләштерү.

3. Кадетлар белеме бирүне үстерүне кадрлар белән тәэмин итү сыйфатын күтәрү, педагогик һәм җитәкче кадрларны беренчел сайлау, квалификацияләрен күтәрү һәм яңадан һөнәри әзерләүне кертеп.

4. Белем бирү процессын мәгълүмати, психологик-педагогик һәм уку-укыту-методик тәэмин итүне үстерү, шул исәптән кадетлар белеме бирү оешмалары педагогларының һөнәри эшчәнлеген консультация-методик яктан тәэмин итүне оештыру.

5. Кадетлар белеме бирү оешмаларының матди-техник базасын ныгыту.

6. Кадетлар белеме бирү оешмаларының социаль партнерлыгын, балаларга өстәмә белем бирү оешмалары, иҗтимагый оешмалар белән үзара хезмәттәшлеген камилләштерү.

7. Кадетлар белеме бирү оешмалары эшчәнлеге сыйфатын бәяләү системасын төзү.

8. Кадетлар белеме бирүне үстерү проблемалары буенча төбәк фәнни тикшеренүләре оештыру.

Кадетлар белеме бирүне үстерүнең максатларын һәм бурычларын тормышка ашыруның иң мөһим шарты булган төп социаль-педагогик принципларга түбәндәгеләр керә:

хәрби даирәдә дә, гражданнар даирәсендә дә дәүләт хезмәтенең югары социаль әһәмиятен тану, дәүләт хакимияте органнарына тугрылык, ватанпәрвәрлек – шәхеснең Ватанга лаеклы хезмәт итәргә әзерлеген билгели торган әхлакый нигезе;

кадетлар белеме бирүнең педагогик мирасы эчтәлеген һәм алдынгы педагогик тәҗрибәне, кадетларның рухи-әхлакый кыйммәтләрен һәм традицияләрен билгеләргә, аларны заманча кадетлар белеме бирү оешмаларында гамәлгә ашырырга мөмкинлек бирә торган фәннилек;

кадетларның төрле яшь һәм категория үзенчәлекләрен исәпкә алып, кадетлар белеме бирүне үстерүдә системалылык, күчә бару һәм өзлексезлек, укучыларны укыту, тәрбияләү һәм үстерү формалары, ысуллары һәм чараларының күптөрлелеге.

Кадетлар белеме бирүнең үзенчәлекле педагогик принциплары булып түбәндәгеләр тора:

үрнәк белән тәрбияләү. Кадетлар, билгеле, форманы кия, матур итеп сөйләшә, дөрес итеп йөри, осанканы тота белүдә педагогларга, тәрбияче-офицерларга охшарга тырышканнар, тырышалар һәм тырышачак. Шуңа күрә тәрбияче-офицерлар, укытучылар үз-үзләренә кадетлар барында, мәсәлән, кулларын кесәдә тотарга, сөйләшү вакытында кулларын селтәргә, жаргон сүзләр кулланырга, җыйнаксыз киенергә яки кырынмаган булырга, тәмәке тартырга юл куймый;

яшьләренә, социаль үткәненә, әти-әниләренең титулларына, чиннарына, матди хәленә, шәхси интеллектуаль һәм физик үсешенә бәйсез рәвештә барлык кадетларның тигезлеге;

хезмәт белән тәрбияләү – кадетларны көнкүрештә үз-үзенә хезмәт итүгә әзерләү, пөхтәлек, намуслылык, теләсә нинди, күңел ятышсыз булса да, әмма кирәкле эшне башкарырга әзерлек формалаштыру һәм башкаларга үзен эшли белгәннәрне өйрәтү. Хезмәт белән җәза бирү катгый тыела.

Татарстан Республикасында кадетлар белеме бирүне үстерүнең төп юнәлешләренә түбәндәгеләрне кертергә була:

норматив-хокукый юнәлеш — дәүләт мәгариф сәясәте нигезендә Татарстан Республикасының төбәк үзенчәлекләрен исәпкә алып, кадетлар белеме бирүне үстерү механизмнарын, институтларын билгели торган норматив база эшләү;

оештыру-идарә юнәлеше — укучыларның белем бирү буенча аерым ихтыяҗларын исәпкә алып, укучыларны тәрбияләүгә һәм аларның уңышлы социальләшүенә социаль-педагогик ярдәм күрсәтү модельләрен, тәрбия,

физкультура-спорт, мәдәни-ял итү программаларын һәм башка программаларны эшләү һәм тормышка ашыру өлкәсендә ведомствоара хезмәттәшлекне оештыру;

кадрлар юнәлеше — кадетлар белеме бирү өлкәсендә квалификация күтәрү, яңадан һөнәри әзерләү буенча өстәмә һөнәри программалар эшләү һәм тормышка ашыру; иң яхшы инновацион белем бирү практикалары банкын тулыландыру; кадетлар белеме бирүнең нәтиҗәле тәҗрибәсен үзләштерү һәм аның белән бүлешү;

мәгълүмат-технология юнәлеше — заманча технологияләр базасында кадетлар белеме бирү оешмалары эшчәнлеген уку-укыту-методик тәэмин итүгә, төбәк белем бирү ресурсларын (массакүләм мәгълүмат чаралары, интернет-сайтлар, мәгариф оешмалары сайтлары сәхифәләре, интернет-конференцияләр, вебинарлар, форумнар һ.б.ш.) җәлеп итеп, белем бирү процессына мәгълүмати ярдәм күрсәтүне оештыру;

мониторинг юнәлеше — кадетлар белеме бирүне үстерү, аның сыйфатын бәяләү буенча чаралар комплексы нәтиҗәлелегенә мониторинг һәм экспертиза оештыру һәм гамәлгә ашыру системасын төзү.

Әлеге юнәлешләрне тормышка ашыру уку-укыту процессында һәм өстәмә белем бирү системасында төп тәрбия юнәлешләрен гамәлгә ашырырга мөмкинлек бирә:

рухи-әхлакый юнәлеш — кадетларның югары кыйммәтләрне, идеалларны һәм ориентирларны, социаль яктан әһәмиятле процессларны һәм чын тормыш күренешләрен аңлап җиткерүе, гамәли эшчәнлектә, үз-үзеңне тотуда төп принциплар, позицияләр буларак аларга таянып эш итү сәләтен формалаштыру. Юнәлеш югары культура һәм укымышлылыкны үстерүне, Ватанга лаеклы хезмәт итәргә әзерлек аның өчен барлыкка килә торган идеяне аңлап җиткерүне, югары әхлакый, һөнәри-этик тәртип нормалары һәм сыйфатлар формалаштыруны: намус, бурыч, җваплылык, присягага һәм кадетлар тугандашлыгына тугрылыкны үз эченә ала;

хәрби-патриотик юнәлеш — Россия җәмгыяте һәм дәүләт үсеше, милли үзаң, яшәү рәвеше, россиялеләрнең дөньяны аңлавы һәм язмышы үзенчәлекләрен чагылдыра торган иң мөһим рухи-әхлакый һәм мәдәни-тарихи кыйммәтләрне формалаштыру. Юнәлеш Ватаныңа фидакарь мәхәббәт һәм тугрылык, бөек халык арасыннан, аның ирешкәннәре, сынаулары һәм проблемаларына бәйле булуың белән горурлану, милли изге урыннарны һәм символларны хөрмәт итү, җәмгыятькә һәм дәүләткә лаеклы һәм фидакарь хезмәт итәргә әзерлек формалаштыруны күздә тота;

һөнәр-эшчәнлек юнәлеше – Ватанга хезмәт итү белән бәйле хезмәткә намуслы һәм җаваплы мөнәсәбәт, хезмәт вазыйфаларын һәм куелган бурычларны уңышлы үтәү йөзеннән һөнәр-хезмәт сыйфатларын актив белдерүгә омтылыш формалаштыру. Юнәлеш шәхеснең һөнәр-эшчәнлек ягыннан үзбилгеләнү мотивларын, максатларын һәм бурычларын, кыйммәти ориентацияләрен, һөнәри дәгъва итү һәм югары эшчәнлек нәтиҗәләренә ирешүгә омтылышны, вазыйфаларыңны югары нәтиҗәлелек белән башкару һәм конркет максатларга ирешү сәләтен, һөнәри үсеш планнарын фаразлый һәм гамәлгә ашыра белүне үз эченә ала;

психологик-педагогик юнәлеш – кадетларда югары психологик тотрыклылык, теләсә нинди шартларда катлаулы һәм җаваплы бурычларны башкаруга әзерлек, дәүләт хезмәтенең хәрби һәм башка төрләрендә авырлыклар һәм кыенлыкларны

җиңеп чыгу сәләтен, коллективта уңышлы эшчәнлек һәм тормыш өчен кирәкле мөһим психологик сыйфатларны формалаштыру;

сәяси-хокукый юнәлеш – конституцион һәм хәрби бурычны, җәмгыятьтә һәм дәүләттә сәяси һәм хокукый вакыйгалар һәм процессларны, хәрби сәясәтне, илнең һәм хәрби доктринаның милли куркынычсызлык концепциясенең төп нигезләмәләрен, җәмгыять һәм дәүләтнең сәяси системасында Россия Федерациясе Кораллы Көчләренең урынын һәм ролен тирәнтен аңлауны формалаштыру. Юнәлеш дәүләт законнары, аеруча Россия гражданы хокуклары һәм бурычлары, җәмгыятьнең хәрби оешмасы эшчәнлеге функцияләре һәм хокукый нигезләре белән таныштыруны, хәрби присяга нигезләмәләрен аңлауны үз эченә ала;

сәламәтлек саклау юнәлеше – тормышка һәрьяклап, әйләнә-тирә мохит сыйфатына, үзеңнең сәламәтлегеңә, əти-әниең, гаилә әгъзаларың, педагогларың, яшьтәшләреңнең сәламәтлегенә кыйммәти мөнәсәбәт формалаштыру. Әлеге юнәлеш спорт һәм физик культура, сәламәт һәм имин яшәү рәвеше әһәмиятен, сәламәт кешенең һәм әйләнә-тирәсенең экологиясе торышының үзара бәйләнешен, шәхси һәм җәмәгать сәламәтлеген һәм иминлеген тәэмин итүдә физик культураның ролен аңлауны; тәмәке тартуга, алкогольле эчемлекләр, наркотиклар, башка психоактив матдәләр куллануга тискәре мөнәсәбәт раслауны үз эченә ала.

Концепцияне тормышка ашыруның төп этаплары билгеләнде.

I этап — 2017 ел:

Татарстан Республикасында кадетлар белеме бирүне үстерү концепциясен раслау.

II этап — 2017 — 2018 еллар:

кадетлар интернат мәктәпләре, кадетлар мәктәпләре һәм Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында кадетлар сыйныфлары эшләвенең норматив-хокукый һәм оештыру ягыннан механизмнарын эшләү;

кадетлар интернат мәктәпләре, кадетлар мәктәпләре һәм гомуми белем бирү оешмаларында кадетлар сыйныфлары инфраструктурасын үстерүнең бертип модельләрен эшләү. Республика кадетлар интернат мәктәбе (мәктәбе), кадетлар мәктәпләре һәм гомуми белем бирү оешмаларындагы кадетлар сыйныфларының матди-техник һәм уку-укыту базасын яхшырту буенча чаралар программасын кабул итү;

кадетлар белеме бирү максатларын һәм бурычларын хәл итү өчен, өстәмә гомуми үстерүче программалар белән бергә төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыру үзенчәлекләрен исәпкә ала торган белем бирү программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнарны билгеләү буенча Татарстан Республикасы норматив-хокукый актын кабул итү;

кадетлар белеме бирү максатларын һәм бурычларын хәл итү өчен, өстәмә гомуми үстерүче программалар белән бергә төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыру үзенчәлекләрен исәпкә ала торган үрнәк мәгариф программаларын эшләү һәм алар нигезендә кадетлар интернат мәктәбе һәм кадетлар мәктәпләре, кадетлар сыйныфлары тарафыннан белем бирү программаларын эшләү;

кадетлар интернат мәктәпләренә, кадетлар мәктәпләренә, гомуми белем бирү

оешмаларында кадетлар сыйныфларына укырга кабул итү кагыйдәләрен эшләү;

кадетлар интернат мәктәпләрендә һәм кадетлар мәктәпләрендә, кадетлар сыйныфларында эшләү өчен педагогик хезмәткәрләрнең һәм педагогик эшчәнлеккә мотивлашкан затларның квалификациясен күтәрү һәм аларны яңадан һөнәри әзерләү программаларын эшләү һәм гамәлгә кертү.

III этап — 2018 — 2020 еллар:

Концепцияне тормышка ашыру барышын һәм нәтиҗәләрен бәяләү. Алдагы этапларда алган нәтиҗәләрне гамәлгә кертү һәм таратуга юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыру.

## III. Көтелә торган нәтиҗә

Концепцияне тормышка ашыру, түбәндәге нәтиҗәләргә ирешү нигезендә үзгәреп торган шартларны исәпкә алып, кадетлар белеме бирү системасын үстерүне тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк:

Татарстан Республикасында кадетлар белеме бирүнең оптималь системасын концептуаль һәм норматив-хокукый тәэмин итү;

кадетларның хәрби-патриотик һәм рухи-әхлакый үсешен тәэмин итү, бербөтен граждан үзаңы, уртак культура, сәламәт яшәү рәвеше формалаштыру, һөнәри үзбилгеләнү йөзеннән республиканың кадетлар белеме бирү оешмаларында нәтиҗәле тәрбия бирү системасын төзү;

республиканың кадетлар белеме бирү оешмаларының инновацион тәрбия бирү тәҗрибәсе белән уртаклашу һәм аны үзләштерү;

кадетлар белеме бирү оешмаларының педагогик һәм идарә кадрларының заманча шартларда эшләүгә әзерлеген формалаштыру, аларның квалификациясен күтәрү һәм яңадан һөнәри әзерләү, шул исәптән кадетлар белеме бирүне тормышка ашыру максатларында, заманча белем бирү технологияләрен һәм методикаларын үзләштерүен үз эченә алган;

заманча мәгълүмат-коммуникация технологияләреннән, челтәр аша хезмәттәшлек итүдән файдаланып, кадетларны укыту, тәрбияләү һәм үстерүне оештыру;

кадетлар белеме бирү оешмаларының матди-техник базасын ныгыту;

белем бирү оешмаларында укучыларның хәрби яки башка дәүләт хезмәтен сайлауга ныклы мотивациясен формалаштыру, ярдәм күрсәтү һәм үстерү буенча максатчан һөнәри ориентация эше системасын төзү;

яшьләр арасында дәүләт хезмәтенең, аеруча хәрби, дәрәҗәсен күтәрү;

укучыларның һәм ата-аналарының кадетлар белеме бирү оешмаларында укыту, тәрбияләү һәм үстерү шартлары белән канәгатьлеген арттыру;

актив тормыш позициясен, иҗади эшчәнлектә мөстәкыйльлек һәм иҗади инициатива, тормышка, әйләнә-тирә мохиткә җаваплы мөнәсәбәт күрсәткән, патриотик, рухи-әхлакый кыйммәтләрне яклаган кадетларның чагыштырма авырлыгын арттыру;

кадетлар белеме бирү оешмаларында укучыларны социаль яклау дәрәҗәсен күтәрү.

---